**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 29 гыйнварындагы 233 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 22 декабрендәге 4604 номерлы «Казан шәһәренең Совет районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Техник хата булу сәбәпле, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 22 декабрендәге 4604 номерлы «Казан шәһәренең Совет районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына, 1.1 пунктчасында «хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы: 16:50:250230» сүзләрен «хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы: 16:50:150413» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карар нигезендә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**